КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 6 апрель г.Казань № 219

«Холмогоры - Клин» магистраль нефть үткәргечен эксплуатацияләү максатларында Татарстан Республикасының «Уланово – Каратун» – Кабы-Копри», «Уланово – Каратун», «Уланово – Каратун» – Зур Кайбыч», «Казан – Малмыж», «Арча – Сиза», «Арча – Теләче», «Урта Кушкет – Югары Субаш», «Карадуган – Югары Шубан» – Ярак-Чурма», «Буа – Яльчик», «Вольный Стан – Киять – Яшевка», «Казан – Ульяновск» – Кама Тамагы», «Столбище – Атабай», «Саескан Тавы – Шәле» гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полоса чикләрендә «Транснефть - Прикамье» акционерлык җәмгыяте мәнфәгатьләрендә гавами сервитутлар билгеләү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының төбәк яисә муниципальара әһәмиятле гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары исемлеген раслау турында» 2019 ел, 17 октябрь, 916 нчы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәнең 3.3.102.1 пунктына таянып, «Транснефть - Прикамье» акционерлык җәмгыятенең 2021 елның 01 февралендәге 16 номерлы мөрәҗәгате нигезендә, «Холмогоры - Клин» магистраль нефть үткәргечен эксплуатацияләү максатларында Татарстан Республикасының «Уланово – Каратун»

– Кабы-కопри», «Уланово – Каратун», «Уланово – Каратун» – Зур Кайбыч», «Казан – Малмыж», «Арча – Сиза», «Арча – Теләче», «Урта Кушкет – Югары Субаш», «Карадуган – Югары Шубан» – Ярак-Чурма», «Буа – Яльчик», «Вольный Стан – Киять – Яшевка», «Казан – Ульяновск» – Кама Тамагы», «Столбище – Атабай», «Саескан Тавы – Шәле» гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полоса чикләрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. “Транснефть - Прикамье” акционерлык җәмгыяте мәнфәгатьләрендә 49 елга кушымта нигезендә җир кишәрлекләренә карата гавами сервитутлар урнаштырырга (420081, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Патрис Лумумба ур., 20 йорт, ИНН 1645000340, ОГРН 1021601763820).

2. «Холмогоры – Клин» магистраль нефть продуктлары үткәргечен эксплуатацияләү максатларында билгеләнә торган гавами сервитутлар чикләре урынының кушымтада бирелгән график тасвирламасын расларга.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән гавами сервитутлар өчен түләү Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{46}$ статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренә мөнәсәбәттә сервитут урнаштыру турында килешү буенча түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 28 сентябрь, 712 нче карары нигезендә билгеләнә дип билгеләргә.

4. «Транснефть - Прикамье» акционерлык җәмгыятенә кушымтада күрсәтелгән җир кишәрлекләрендә эшләр башланганчы ук «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тотуның һәм үстерүнең төп идарәсе» дәүләт казна учреждениесе белән килешү төзергә тәкъдим итәргә, ул гавами сервитут билгеләү өчен түләү күләмен күздә тота.

5. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына законда билгеләнгән вакытта әлеге карарның билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәләрен Татарстан Республикасы буенча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсенә, «Транснефть - Прикамье» акционерлык җәмгыятенә, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын тоту һәм үстерүнең төп идарәсе» дәүләт казна учреждениесенә җибәрергә.

7. «Транснефть - Прикамье» акционерлык җәмгыятенә кушымтада күрсәтелгән җир кишәрлекләрен аларның рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә, ачык сервитут нигезендә урнаштырылган инженерлык корылмасын, тәэмин ителеше өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң, Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{50}$ статьясында билгеләнгән вакытларда сүтергә.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 6 апрель, 219 нчы
карарына кушымта

«Транснефть - Прикамье» акционерлык җәмгыяте мәнфәгатьләрендә гавами сервитутлар билгеләнә торган җир кишәрлекләре исемлеге

| Т/с | Җир кишәрлегенең кадастр саны | Җир кишәрлегенә хокук иясе | Хокук төре | Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр нигезендә җир кишәрлегенең урнашу урыны | Сервитут урнаштырыла торган җир кишәрлегенең мәйданы, кв. метр |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | 16:08:000000:84 | Татарстан Республикасы | милек | Татарстан Республикасы, Апас муниципаль районы, Сатламыш авыл җирлеге | 984 |
| 2. | 16:08:080402:95 | Татарстан Республикасы | милек | Татарстан Республикасы, Апас муниципаль районы, Югары Ындырчы авыл җирлеге | 1 156 |
| | | «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе | даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану | | |
| 3. | 16:08:000000:84 | Татарстан Республикасы | милек | Татарстан Республикасы, Апас муниципаль | 494 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | районы, Сатламыш авыл җирлеге | |
| 4. | 16:08:000000:84 | Татарстан Республикасы | милек | Татарстан Республикасы, Апас муниципаль районы, Шәмбалыкчы авыл җирлеге | 1 065 |
| 5. | 16:09:000000:593 | Татарстан Республикасы | милек | Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Үрнәк авыл җирлеге | 1 255 |
| | | «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе | даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану | | |
| 6. | 16:09:000000:566 | Татарстан Республикасы | милек | Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Урта Корса авыл җирлеге | 1 009 |
| | | «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе | даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану | | |
| 7. | 16:09:000000:583 | Татарстан Республикасы | милек | Татарстан Республикасы, Арча муниципаль | 895 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе | даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану | районы, Төбәк-Чокырча авыл җирлеге | |
| 8. | 16:12:040702:47 | дәүләт милке чикләнмәгән | дәүләт милке чикләнмәгән | Татарстан Республикасы, Балтач муниципаль районы, Югары Субаш авыл җирлеге, «Таң» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы хуҗалыгы | 160 |
| 9. | 16:12:170604:28 | дәүләт милке чикләнмәгән | дәүләт милке чикләнмәгән | Татарстан Республикасы, Балтач муниципаль районы, Шубан авыл җирлеге, «Алга» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы хуҗалыгы | 623 |
| 10. | 16:14:000000:692 | Татарстан Республикасы | милек | Татарстан Республикасы, Буа муниципаль районы, Рунгин авыл җирлеге | 840 |
| | | «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш | даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | идарәсе» дәүләт казна учреждениесе | | | |
| 11. | 16:14:000000:513 | Татарстан Республикасы | милек | Татарстан Республикасы, Буа муниципаль районы, Альшихово авыл җирлеге | 1 101 |
| | | «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе | даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану | | |
| 12. | 16:15:000000:476 | Татарстан Республикасы | милек | Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Шылаңгы авыл җирлеге | 911 |
| | | «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе | даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану | | |
| 13. | 16:24:000000:151 | Татарстан Республикасы | милек | Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Никольское авыл җирлеге | 1 079 |
| | | «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе | даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 14. | 16:33:170414:294 | Татарстан Республикасы | милек | Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Шәле авыл җирлеге | 3 072 |
| | | «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе | даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану | | |
| Барлыгы | | | | | 14 644 |